УДК 821.512.145

# РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИННЕҢ ИҖАТЫНДА МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК ЭСТЕТИКАСЫ ЧАГЫЛЫШЫ

***Ә.М. Закирҗанов***

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*alfat_zak@mail.ru*

XIX йөз урталарында Россиянең татарлар яшәгән төбәкләрендә акыл, белем, әхлак нигезендә җәмгыятьне үзгәртүне максат иткән мәгърифәтчелек хәрәкәте башлана. Ул әдәбиятка да көчле тәэсир ясый һәм әдипләр мәгърифәтчелек идеяләрен яклауның, халыкка җиткерүнең юлларын, алым-чараларын эзләүгә алыналар. Татар Яңарышына зур өлеш керткән Ризаэддин Фәхреддин *«Сәлимә»*, *«Әсма»* повестьларында чынбарлык вакыйгаларына мөрәҗәгать итеп, укымышлы, халык мәнфәгатен кайгыртып яшәүче идеаллаштырылган геройларны алга чыгара. Автор җәмгыятьтәге үзгәрешләрне хатын-кыз язмышы белән тыгыз бәйләнештә карый. Әсәрләрдә ислам дине кыйммәтләре рус-Европа казанышлары белән үрелеп бирелә. Әдип яшәеш үзәгенә Кешене куя, аның белемле һәм әхлаклы булуын яклый. Әсәрләргә синкретизм хас булып, аларда авторның дини-этик, фәлсәфи-эстетик карашлары чагыла.

**Төп төшенчәләр:** мәгърифәтчелек, татар әдәбияты, Ризаэддин Фәхреддин, хатын-кыз язмышы, гаилә, әдәби-эстетик карашлар, ислам кыйммәтләре

**Сылтама ясау өчен:** Закирзянов А.М. Ризаэддин Фәхреддиннең иҗатында мәгърифәтчелек эстетикасы чагылышы // Историческая этнология. 2020. Т. 5, № 2. С. 293–305. https://doi.org/10.22378/he.2020-5-2.293-305

XIX йөз ахыры – XX йөз башы татар мәдәнияте, әдәбияты, иҗтимагый фикере үсешендә гаять зур урын биләгән, энциклопедик характердагы эшчәнлек алып барган олуг шәхесләрнең берсе – Ризаэддин Фәхреддин. Ул дин һәм җәмәгать эшлеклесе, тарихчы-галим, әдип, педагог, журналист буларак танылу ала һәм һәр тармакта яңа сүз әйтеп, аның үсеш-үзгәрешенә көчле йогынты ясый.

Р. Фәхреддиннең татар әдәбияты Яңарышында лаеклы урын алып торган әдәби иҗаты үз вакытында ук киң җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итә. Әдипнең *«Сәлимә, яки Гыйффәт»* (1899) һәм *«Әсма, яки Гамәл вә җәза»* (1903) китапларында XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар тормышының иҗтимагый-мәдәни, дини-фәлсәфи, әдәби-эстетик проблемалары чагылыш таба. Р. Фәхреддиннең кызы Әсма Шәрәф үзенең истәлегендә этисенең мондый сүзләрен китерә: *«Сәлимә»* белән *«Әсма»*ны язуыма сәбәп роман тәртип итү генә түгел иде, бәлки күңелгә урнашкан файдалы фикерләрне үз телебездә язып, укучыларга ирештерү иде. Духовное собраниедә эшләвем аркасында, шул әсәрләр хакында булачак яхшы вә яман фикерләрне язганны иркенләп ишетер өчен, әсәрләргә үземнең исемемне куймадым, псевдоним белән язган идем. *«Сәлимә»* турында яманлап, гаеп итеп язган сүзләр күп булган, хәтта Духовное собрание исеменә авторны гаепләп зур жалоба язганнар. Барча яманлап язылган язулар *«Сәлимә»*дән зур күләмдә булган» (Шәрәф 1999: 48). Аңлашылганча, истәлектә тәнкыйди фикерләр турында сүз барса да, хуплап чыгулар да аз булмагандыр дип уйларга нигез бар. Ә инде берникадәр вакыттан соң, матбугат битләрендә әлеге әсәрләр турында тәнкыйди язмалар да урын ала. Беренчеләрдән булып бәя биргән Г. Тукай *«Ялт-йолт»* журналы мөхәррире Әхмәт Урманчиевка хатында болай яза (1912): «Риза казый “Әсма”, “Сәлимә” кеби китаплары белән язу көче вә хәтта шигъриясен күрсәткән вә гомумән хикәяләве ачык, язу стиле садә вә гүзәл бер язучыдыр» (Тукай 2016: 232). Р. Фәхреддиннең әдәби иҗатын фәнни планда тикшергән Җ. Вәлиди аның әсәрләрендә дин һәм мәдәният мәсьәләләренең гармоник кушылып китүен билгели, авторның әдәби чаралар белән реформаторлык идеяләрен яклавын, шуңа да урыны белән сөйләү һәм вәгазь белән мавыгуын күрсәтә (Валидов 1998: 125–127). Атаклы мәгърифәтченең киңкырлы эшчәнлеген, шул исәптән әдип буларак иҗат үзенчәлекләрен киң планда өйрәнү XX гасырның 60–70 нче елларында М. Гайнуллин, М. Госманов, М. Гайнетдинов, Ф. Баишев, Ф. Мусин һ.б. тырышлыгы белән башлана. Ә инде үткән гасырның 90 нчы елларында бу эшнең тарихи-фәлсәфи, дини-әдәби, әхлакый-эстетик яссылыкта тирәнәюе Г. Хөсәенов, М. Рәхимкулова, Ә. Хәйри, М. Әхмәтҗанов, Р. Үтәбай-Кәрими, Х. Миңнегулов, Б. Солтанбәков, Д. Гарифуллин, Р. Мәрданов, Г. Даутов һ.б. исемнәре белән бәйле. Р. Фәхреддин хезмәтләренең киң катлау укучыларга килеп җитүендә Ә. Хәйри һәм Р. Әмирхан аеруча зур хезмәт куя. Л. Хәйдәров тырышлыгы белән *«Сәлимә»* һәм *«Әсма»* әсәрләре тулы күләмдә һәм хәзерге заман татар әдәби теленә яраклаштырып бастырып чыгарыла (Фәхреддин 2018).

Р. Фәхреддин иҗатын ул яшәгән, белем алган чор үзенчәлекләре, җәмгыятьтә өстенлек иткән караш-фикерләр, татар әдәбиятының торышы кебек мәсьәләләр белән тыгыз бәйләнештә генә тулы аңлап була. Билгеле булганча, XIX гасыр урталарында татар халкының иҗтимагый-мәдәни тормышында җитди үзгәрешләр башлана (Закирзянов 2019: 85).

Җәмгыятьтә үзләрен татар милләте вәкилләре дип күзаллаган һәм халыкның мәдәни дәрәҗәсен Аурупа халыкларына якынайтырга омтылган шәхесләр үсеп чыга (Юзеев 2001: 144–146). Р. Фәхреддин әнә шундыйларның берсе буларак, табигать биргән сәләтен, көчен халкына ихлас хезмәт итүгә багышлый. Ул моңа мәдрәсә елларыннан башлап әзерләнә һәм гомере буе әлеге кыйбласына тугры кала.

Аның иҗтимагый-педагогик карашларына И. Гаспралы мөхәррирлегендә Кырымда чыгып килгән *«Тәрҗеман»* газетасының йогынтысы булуда шик юк. 1883 елда чыга башлаган газета турында ишетүгә, Фәрид исемле иптәше белән редакциягә хат яза һәм 1984 елдан башлап алдырып укый башлый. Бу турыда истәлегендә болай яза: «Шуннан исә бу көнгә кадәр бер санын да кулдан ычкындырмый укып килдем» (Фәхреддин 1999: 20). Атасы Фәхреддин хәзрәт, анасы Мәхүбә абыстайның укымышлы руханилар нәселеннән булулары билгеле. Ризаэддиннең апасы ахун Гыйльман әл-Кәримигә кияүгә чыга. Әлеге ике затлы гаиләнең туганлыгы, һичшиксез, бер-берсен рухи яктан үстерүгә ярдәм иткән[1].

Кызы Әсма аны болай характерлый:

> «Әткәй сабыр холыклы, йомшак табигатьле кеше иде. Һичбер вакытта каты сүз белән кешенең хәтерен калдыра торган булмады. Кем белән генә сөйләшкәндә дә кадерле гадәте бар иде: сөйләшкән кешенең сүзен сабырлык белән актыгына хәтле бүлмичә тыңлап тора да, сүз беткәч, үзенең сүзен, җавабын, фикерен сөйли иде. Сөйләгәндә, гадәтенчә, бик төзек, конкрет сөйли иде, мәгънәсез сүзләр катнаштырмый иде. Үзе белгән, үзен хаклы итеп тапкан очракта үзенең фикерен, риза булмаганын һәркемгә ачыктан-ачык әйтә торган, батыр йөрәкле, курыкмас кеше иде» (Шәрәф 1999: 74).

Р. Фәхреддингә тырышлык, хезмәт сөючәнлек хас булып, хезмәттә җан тынычлыгы, рухи көч таба. «Ул бөтен барлыгы, меңнәрчә тамырлары белән татар җире, татар рухы белән бәйләнгән зат. Халыкка, хакыйкатькә хезмәт итү, иманга тугрылык – Р. Фәхреддин яшәешенең асыл максаты» (Миңнегулов 2004), – дип яза Х. Миңнегулов мәгърифәтче-галим эшчәнлегенең төп кыйммәтен билгеләп.

Бу чорда ислам динен реформалаштыру, аны чорга, заманга яраклаштыру мәсьәләсе көчле бәхәсләр тудыра. Бу өлкәдә Ш. Мәрҗанинең роле гаять зур була.

> «Татарское религиозное реформаторство конца XVIII–XIX вв., как составная часть татарской общественной и философской мысли, сыграло свою роль в развитии общественного сознания мусульманского населения, через рационалистическую критику устоявшихся взглядов на отдельные положения религии подготавливая его умы для восприятия нового образа мышления, соответствующего эпохе

[1] Гыйльман ахун улы Фатих Кәрими танылган әдип, журналист, җәмәгать эшлеклесе булып китә.

нового времени» (Очерки истории татарской общественной мысли 2000: 112).

Яңару хәрәкәтенең зур бер тармагы булып мәдәният тора. Әлеге киң мәгънәдәге төшенчә, бер яктан, мәктәп-мәдрәсәләрне үзгәртеп коруны, дин белән бергә дөньяви фәннәр укытуны һәм башка халыклар мәдәниятендәге казанышларны өйрәнүне күздә тота (Габидуллина 2016: 6–7). Мәгърифәт мәсьәләсенә җитди игътибар бирелеп, ул милләтнең киләчәге белән бәйләп карала. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татар Яңарышының яңа баскычы рәвешендә таралыш алган җәдитчелек яшәешнең икътисад һәм сәясәт өлкәләренә дә тирән үтеп керә. Д. Исхаков фикеренчә, татарларның милли үзаңы үсеше, аларның Россия империясендә милли тигезлеккә ирешү кирәклеген аңлауга китерәчәк. Ә бу исә артта калганлыкны бетерү аша руслар белән башта мәдәни, аннары сәяси тигезлеккә ирешү омтылышына юл ача (Исхаков 1997: 8).

XIX йөзнең икенче яртысында җәмгыятьнең бөтен өлкәләренә үтеп кергән мәгърифәтчелек хәрәкәте әдәбият үсешенә дә көчле йогынты ясый. Тормышны акыл, белем, әхлак ярдәмендә үзгәртеп коруны максат иткән мәгърифәтчелек идеологиясе әдәбиятның тематикасын, идея юнәлешен, жанр төрлелеген, иҗат алымнарын һәм иҗат методын билгели. Халыкка якынрак булу өчен әдипләр чынбарлыктагы реаль күренешләргә активрак мөрәҗәгать итәләр. Бу исә реализмның торган саен киңрәк урын алуына китерә. Тормышны бөтен тулылыгында чагылдыру исә, тезмә әсәрләр белән бергә, проза һәм драматургиянең мәйданга чыгуын тизләтә һәм бу чорда яңа төрләр, жанрлар барлыкка килә. Милләтнең алга китүенә, мул тормышка чыгуына ирешү өчен, иң элек аңа аң-белем бирергә, тәрбияләргә кирәк була. Матур әдәбият яңа фикер-идеяләрне кеше күңеленә, аңына сеңдерүдә үтемле чара булганлыктан, мәгърифәтчелек хәрәкәте аны үз идеяләрен тарату-үткәрүдә мөһим чара буларак файдалана. Әдәбияттагы сыйфат үзгәрешләренең иң мөһиме – яңа, реалистик әдәбият формалаша башлау белән бәйле. Ул исә мәгърифәтчелек идеалларына нигезләнә, шуларга зур өметләр баглый. Әдипләрнең дөньяга карашындагы, сәнгатьчә фикерләвендәге үзенчәлекләр мәгърифәтчелек реализмы методының җирләшүе турында сүз алып бару мөмкинлеге бирә. Билгеле инде, әлеге сәнгати фикерләүгә нигезләнгән әдипләр иҗаты бертөрле генә түгел. Шуңа да мәгърифәтчелек реализмына нигезләнсәләр дә, М. Акъегетзадә һәм З. Бигиевнең әдәби-эстетик карашлары бераз соңрак мәйданга килгән Ф. Кәрими, Р. Фәхреддин, Г. Исхакый, З. Һади, Ш. Мөхәммәдев, Г. Камал һ.б. әдипләрнең сәнгати фикерләвеннән шактый аерыла.

Мәгърифәтчелек халык тормышының бөтен ягын диярлек иңләп ала һәм һәр өлкәдә яңарыш-үзгәрешләргә юл ача. Мәгърифәтчелек – фәлсәфи, этик һәм эстетик карашлар системасы ул. Алгы планга исә халыкны аңбелемле итүне, әхлак сыйфатлары тәрбияләүне чыгара. Шуңа да мәгърифәтчеләрнең караш-фикерләрен әдәби әсәрләрдә чагылдыручы язучылар әхлакый кануннарга нигезләнеп яшәүче мәгърифәтле кеше тормышта

бәхетле була дип ышаналар. Әлеге идея бу чорда дөнья күргән әсәрләрнең барысында да диярлек чагылыш таба.

Мәгърифәтчелек мәсьәләләре арасында мәктәп-мәдрәсәләрдәге уку-укыту системасын үзгәртү мөһим урын алып тора. Билгеле булганча, әлеге уку йортлары дини белем бирүне алгы планга куялар һәм шәкертләрне дә шул максатта тәрбиялиләр. Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, XVI гасыр уртасыннан алып XVIII гасыр ахырына кадәрге торгынлык чорында дини башлангыч аеруча көчәя. Татар халкы этнос буларак сакланышын ислам динендә күрә.

> «Колониальный гнет, приведший к обскурации и консервации общественной и духовной жизни татар, декадансу умонастроений во второй пол. XVI – первой пол. XIX вв., органически сросся с суфийской литературой, коранической философией терпения. Именно эта особенность средневекового декаданса помогла татарскому этносу спасти себя от физической гибели, сберечь традиционные ценности исламской культуры» (Ганиева 2005: 10), – дип яза Р. Ганиева.

Р. Фәхреддиннең әдәби иҗатында урын алган әлеге күпсанлы мәсьәләләр арасында аның бөтен иҗатын бербөтенгә туплый торган, дөньяга карашын, яклаган концепциясен билгеләргә ярдәм иткән берничә концептуаль караш бар. Алар түбәндәгеләр: 1. Мәгърифәтченең Шәрык цивилизациясе тудырган казанышларга таянуы, аны яңа шартларда яңа эчтәлек белән баетып үстерүе, аерым алганда мөселман дөньясындагы Акыл һәм Гыйлем культына баш июе. 2. Рухи һәм мәдәни артталыктан чыгу юлларын эзләве, моның өчен Шәрык белән бергә рус-Аурупага йөз белән борылуны хуплавы. 3. Әдәби һәм педагогик хезмәтләрендә милли мәгариф системасының нигезләрен салып калдыруы. 4. Укыту-тәрбия мәсьәләләрендә халык педагогикасына, ислам динендәге тәрбия нигезләренә, үз тәҗрибәсенә таянуы, кешене «камил инсан» итеп саклап калуда белем-тәрбия көченә ышануы. 5. Татар җәмгыятен үзгәртүгә бәйле күптөрле мәсьәләләрне хатын-кызның гаиләдәге һәм җәмгыятьтәге урыны белән бәйләнештә каравы. Әлеге һәм башка мәсьәләләргә киңрәк тукталыйк.

Р. Фәхреддиннең *«Сәлимә, яки Гыйффәт»* повесте Гафил бине Габдулла тәхәллүсе белән басыла. Әсәрнең төп эчтәлеге ул чорда киң таралган сәяхәт кылу вакыйгасына нигезләнеп ачыла. Ун ел мәдрәсәдә белем алган, әмма үз-үзеннән, яшәешеннән ризасызлык хисе дөнья күреп кайтырга әтәргән татар шәкерте пароходта Иран бае кызы Сәлимә белән таныша һәм бергәләп Бакуга кадәр сәяхәт итәләр. Аларның танышлыгы ахырда никахлашу белән тәмамлана. Вакыйгаларны бу рәвешле сурәтләү авторга үзенең карашларын тулырак чагылдырырга мөмкинлек бирә. Чит илдән килгән Сәлимә туташның киң белемле, тәрбияле, акыллы булуы татар шәкерте белән чагыштырыла һәм, ак җаймадәге кара тап сыман, татар тормышының, шул чор җәмгыятенең кимчелекләре аермачык күз алдына бастырыла.

Авторның мәгърифәтчелек карашлары әсәр башында ук, татар шәкертенең дуслары оештырган озату мәҗлесендә сөйләгән сүзләрендә күренә. Мәдрәсә тәмамлаган укымышлы кеше нинди булырга, үзенең белемен, тырышлыгын нәрсәгә юнәлтергә тиеш соң? Менә алар: 1) ата-ана тәрбиясенең әһәмиятен аңлап, яхшы ата булырга; 2) җәмгыять хәлен, ягъни милләт язмышын кайгыртып яшәргә; 3) чит халыклардан гыйбрәт алырга һәм дә 4) бабаларыбызның эшчәнлеген онытмаска, алардан да үрнәк алырлык нәрсәләр күп; 5) күп төрле телләрне яхшы белергә; 6) мәдрәсәләрдә укыту эшләрен яхшыртырга. Күргәнебезчә, шәкерт дөньяга аек күз белән карый. Әмма белеме һич тә җитәрлек түгел, шуңа да автор аны Сәлимә белән чагыштыра. Шәкерт үзе дә моны аңлый. Бигрәк тә ул һөнәр, сәнгать, тарих мәсьәләләре буенча әзерлексез.

Авторның төп игътибары юнәлтелгән Сәлимә туташ Иранда укыган, аннары Мисыр университетын тәмамлаган. Ул фарсы, гарәп, инглиз, француз телләрен бик яхшы белә. Әнә шундый тәрбияле, белемле кыз шәкертне битараф калдырмый:

> «Сәлимә туташ әдәпле булган дәрәҗәдә гаҗәеп, гыйлемле булган дәрәҗәдә саф-чиста иде. Май кебек йомшак, сандугач сайравы шикелле моңлы һәм мөлаем тавышлары таң җиле рәвешендә җанымны рәхәтләндерде. Мәхәббәтле караулары, миһербанлы сүзләре, чыбыклар аша тәэсир иткән электр тогы куәте шикелле, бар тәнемә тәэсир итте. Әмән, йа Раббым, никадәр гүзәл һәм сөйкемле иде!» (Фәхреддин 2018: 26)

Сәлимә, француз телендәге китаплар аша укып, төркиләр һәм болгарлар турындагы белемнәре белән дә шәкертне шаккатыра. *«Сәлимә»* повестендагы «Болгар», «Төрки кавемнәр» бүлекләре – «язучының милләт язмышы турында уйлануларының кайтавазы, омтылышларының конкрет гәүдәләнештә тормышка ашырылышы» (Даутов 2001: 46). Әнә шулай тормыш өчен дини белемнәр генә җитмәве, бәлки фәнни белемнәрне үзләштерү кирәклеге ассызыклана.

*«Әсма, яки Гамәл вә җәза»* повесте 1903 елда Оренбургта басыла. Вакыйгалар аша язучы төп әхлакый фикерен үткәрә: яхшылыкның нәтиҗәсе – бәхет, явызлыкның җәзасы – хурлык. Шул рәвешле автор төп идеяне исемгә үк чыгара. Әсәрнең үзәгендә Әсма образы. Аның тормышы, әкият геройларына охшатып, серлелек, маҗаралылык белән бирелә. Повесть башында ук кызның әтисе Габбас мулла алдынгы карашлы, яңалыкка омтылучы кеше итеп сурәтләнә. Габбас мулланың бу дәрәҗәгә ирешүенә хатыны Гайшә абыстайның тәэсире зур булу ассызыклана. Моның белән Р. Фәхреддин хатын-кызның тормыштагы урынына, гаиләдәге хәленә игътибарны юнәлтә. Гайшә абыстай яшь вакытта бер надан, әхлаксыз бай кулына эләкмәвенә сөенеп, Габбас мулла белән аңлашып, ярдәмләшеп яши, кешеләр алдында аның дәрәҗәсен күтәрүгә ирешә. Гомумән, гаиләдә хатын-ир мөнәсәбәте шундый булырга тиеш дигән фикер үткәрелә. Алар бергәләп китаплар, газета-журналлар укыйлар. Әсма әнә шундый шартларда бик

яхшы тәрбия ала. Әмма яхшылык янында яманлык та йөри. Хикмәт хаҗи әхлаксыз кешеләр ярдәмендә тараткан гайбәтләрдән туеп, Габбас мулла хаҗ сәфәренә чыгып китә һәм шунда аның үлеп калуы турында хәбәр килә. Бер елдан соң хатыны Гайшә абыстай да вафат була. Кызлары Әсма, күп төрле маҗараларга эләгә, исемен алыштыра, ахырда тирә-якта дан тоткан Салих байның ятим балалар йортында тәрбияләнә башлый. Монда ул укытучы-мөгаллимә булып җитешә. Бервакыт бай Зәйнәп-Әсманы сораучы ике егет барлыгын әйтә: берсе – бай малае, икенчесе – ярлы укытучы. Кыз соңгысын сайлый. Бу бай хатыннарын гаҗәпкә калдыра. Алар аның турында төрле гайбәт тарата башлыйлар, никахсыз туган кыз, диләр. Зәйнәп-Әсма Салих байга үзенең тормышын сөйләп бирә. Шунда көтелмәгән мәсьәлә ачыклана – Габбас мулла хаҗ сәфәрендә үлмәгән. Төрле хәлләрдән соң исемен «Юныс хәзрәт»кә үзгәртеп, әлеге тәрбия йортында хезмәт итә икән. Әсма кияүгә чыккан егет тә кайчандыр үзара бүләкләр бирешкән шәкерт булып чыга. Әнә шулай яхшы күңелле, инсафлы, намуслы кешеләр барысы да бәхеткә ирешә. Х. Миңнегулов язганча, «Р. Фәхреддин мәхәббәткә, хөрмәт-ихтирамга, үзара җаваплылыкка корылган гаилә тормышын, андагы инсани тәрбияне милләт яшәешенең нигезе, төп шарты дип саный» (Миңнегулов 2003б: 124).

Әсәрдә уңай герой итеп сурәтләнгән образлар арасында Сәлим бабай аерылып тора. Ул халыкның гомумиләштерелгән образы. Тарихны, гыйбрәтле хәлләрне күп белә: «Сәлим бабай ... укылачак бер китаб иде... Бөтен халык бабасы иде... » Әлеге бабай исән вакытта ул белгәннәрнең язып алынмавы өчен үкенү дә белдерелә. Халык иҗат иткән әсәрләрне белү өстенә Сәлим бабай матур итеп җырлый һәм курайда уйный. Аның курай моңы барча кешеләргә бик нык тәэсир итүен сурәтләп, музыканың кеше тормышындагы ролен ачып бирә. Р. Фәхреддин кешегә тәэсир итүче чараларның берсе дип сүз сәнгатен саный. «Әдәбият белән кызыксыну – күңелне сафландыру һәм үз-үзеңне тәрбияләү өчен иң тәэсирле чара. Әдәп китапларын өйрәнү һич вакытта зыян китермәс» (Фәхреддин 2018: 103), – дип яза ул һәм андый китапларның гаиләдә укылу тиешлеген искәртеп китә.

Автор, мәгърифәтчелек традицияләренә тугры калып, уңай геройларга капма-каршы буларак, тискәре образларны сурәтли. Әсәрнең конфликты да искелек белән яңалык бәрелешенә нигезләнә. Повестьта «тәрәккъый тормозлары» итеп Хикмәт хаҗи, Бикбулат мулла, ишан мөриде Муса бирелә. Хикмәт хаҗины әдип «беренче дәрәҗәдә залим» итеп күрсәтә. Ул ерактан торып сәлам бирмәгәннәрдән дә төрлечә үч ала. Аның сәүдәсе дә алдашуга корылган. Яшьлегендә үзе хезмәт иткән байның ике улын төрле бозыклыкларга өйрәтеп, йөзәр тәңкә акча биреп, алардан 20 мең тәңкәлек вексельләр ала. Бай үлгәч, аның хатынына өйләнеп, улларын өйдән куып чыгара. Билгеле инде, аның балалары да шундый ук. Автор Хикмәт хаҗиның дүрт кызын да «агачтан да надан» дип бәяли һәм үзләре шикелле муллаларга кияүгә чыгуларын яза. Бишенче кызын исә Габбас мулла соратачагына шикләнми. Өмете акланмагач,

Габбас мулланы кан дошманы санап, төрлечә түбәнсетү, мыскыллау юлларын эзли башлый. Хикмәт хаҗи тарафдарларының берсе – ишан мөриде Муса, мәчет салырга дип дәфтәр ачып, Габбас мулла исеменнән халыкка үтенеч язып, акча җыярга чыгып китә. Шәһәр байларыннан җыйган акчасын күңел ачу йортында туздырып бетерә. Тикшерү башлангач, Хикмәт хаҗи Габбас мулланы төрмәгә яптыру нияте белән йөри, хәтта адвокат яллый.

Повестьтагы башка тискәре геройларның әхлакый йөзләре шундый ук. Бер мулла, нинди хайван мае икәнлеге безгә мәгълүм түгел дип, керосин лампаларын мәчеттән чыгарткан. Икенчесе, шәм эзләтеп, намаз вакытын бушка уздырган һ.б. Әхлаксыз геройлар үз гамәлләренә күрә җәза алалар. Хикмәт хаҗи бер фәкыйрь мөсафирханәдә вафат була. Хәмидә яман чир эләктерә, Зәйнүш карчык аякларын югалтып, теләнчегә әйләнә. Әсәрдә җәмгыятьнең ямьсез якларын күрсәтүгә дә зур урын бирелгән. Бу Зәйнәп-Әсманың кышкы суыкта теләнеп йөрүе, фәхешханә күренешләре, аерым кешеләрнең ятим балаларны сатып көн күрүләре һ.б. Автор гуманист буларак, болар өчен күңеле белән әрни. Р. Фәхреддиннең публицистик фикерләре аермачык сизелә. Күбрәк ул аларны персонажларның сөйләме аша җиткерә. Яңа мәктәп ачарга рөхсәт сораган крестьяннарны сүгеп җибәргән мулла турында көлеп һәм тәнкыйтьләп яза. Укыту мәсьәләләренә шактый киң урын бирелеп, автор белем алуда укытучы-мөгаллимнең роле, еш кына баланың киләчәге дә шуңа бәйле булу турында уйлана. Автор фикеренчә, гыйлем кешенең башка сыйфатларына да нигез булып тора. Шуңа да белем алып, әдәпле яшәү бәхеткә юл ачкан кебек, аның капма-каршысы булган белемсезлек, наданлык аркасында әдәпсез яшәүгә, ахыр чиктә бәхетсезлеккә дучар булу әсәрләрнең төп идеясе буларак ачыла. Гомумән, «дөрес һәм нәтиҗәле белем ул ахыр чиктә милләтне яңарыш дәверенә алып керәчәк хәлиткеч көч икән» (Бәширов 2003: 237) дигән нәтиҗә ясала.

Яңа ысулны яклаучы геройлары сүз сөйләү белән мавыкмый, бәлки гыйбрәтле мисалларда, гамәлдәге капма-каршылыкта кайсының өстен булуы күрсәтелә. Автор ул чорда күп бәхәсләр уяткан мәсьәләне тарихи агышында карый һәм бүгенге яңа ысулны киләчәктә иске ысул дип әйтерләр, дигән фикерне яклап чыга. Иң мөһиме, кешенең белем алуга теләге булу һәм шул белемнәрен тормышта файдалану икәнлеге гыйбрәтле мисал аша ачыла.

Әсәрләрнең сәнгатьчә эшләнеше, реаль тормыш белән бәйләнеше дә игътибарга лаек. Беренче повестьта Казан турында шактый мәгълүматлар бирелә. Пароходка утыру вакыйгасында хатын-кызлар арасындагы ямьсез, әхлаксыз күренешләргә игътибар юнәлтелә. Повестьта уңышлы китерелгән чагыштырулар («көтүчесе улган хәйваннар сәламәт улдыклары кеби, аталары улган җәмгыятьтә карендәшлек, дустлык улыр»; «май кеби йомшак, сандугач сайравы мисаллы моңлы вә мөлаем тавышлары таң йиле рәвешендә җанымны рәхәтләндерә иде»); мәкаль-әйтемнәр («яшь гомердә

тырышканнар картлыкта рәхәт күрерләр», «гакыл яшьтә улмаз, башта улыр» һ.б.), геройларның портретлары әсәрнең сәнгатьлелеген, укучыга тәэсирен үстерә. Публицистик чигенешләрдә әдип үзе хикәяләүгә катнашып китә, күп мәгълүматлар китерә. Икенче әсәрдә матур чагыштырулар, тасвирлаулар игътибарны җәлеп итә: «Миллион еллардан бирү, урманнарының биеклекләреннән вә яфракларының куелыгыннан, көндез улсын яктылык күрмәмеш урыннары бу көннең электрик нурлары, кояш илә ярышмакта улан яктылыгыны сачып, кояшдан көлеп тормактадыр». Геройларның портретлары да, сөйләмнәре дә истә калырлык итеп, индивидуальләштерелеп бирелә.

Гомумән, Р. Фәхреддиннең *«Сәлимә»* һәм *«Әсма»*сы мәгърифәтчелек реализмы методына нигезләнеп язылганнар. Мәгърифәтче әдипләргә хас булганча, вакыйганың кайда һәм кайчан баруы, таныш шәһәр, елга һ.б. исемнәр атала. Әсәрләргә синкретизм хас, ягъни авторның әдәби сурәтләвенә тормыш-яшәеш, милләт, аның үткәне, бүгенгесе, кеше язмышы, аның бәхете, мәхәббәте турындагы уйланулар кушылып китә һәм үзенчәлекле синтез тәшкил итә. М. Гайнетдинов язганча, аларда «чорның конкрет сорауларына җавап эзләү, шул мәсьәләләр хакында чордашлары белән әңгәмә, чор “публицистикасы” өстенлек итә» (Гайнетдинов 2003: 226–227). Р. Фәхреддин повестьларында романтик тенденцияләр дә урын алган. Дөрес, тулы канлы иҗат ысулы турында сүз бармый, бәлки мәхәббәтне, аерым геройларны идеаллаштыруда, тормышны, киләчәкне матур итеп күрергә теләүдә, матурлык һәм ямьсезлек эстетик категорияләренә мөрәҗәгать итүдә реализмның бер сыйфат-билгесе буларак ачыла.

Шулай итеп, Р. Фәхреддин әсәрләрендә үз чорының актуаль, җәмәгатьчелекне борчыган мәсьәләләре күтәрелә һәм алар мәгърифәтчелек идеаллары яктылыгында хәл ителә. Әсәрләргә синкретизм хас булып, ул «авторның кеше, тормыш, тарих, милләт турындагы уйлануларының бер синтезы» (Миңнегулов 2003а: 109) рәвешендә урын ала. Автор әсәрләрдә ислам дине белән бәйле кыйммәтләргә киң таяну белән бергә, рус һәм Аурупа казанышларын өйрәнү, үзләштерүне дә яклый. Р. Фәхреддин повестьларының үзәген хатын-кыз язмышына бәйле вакыйгалар алып тора, алар «милләт анасы» буларак бәяләнеп, төп сыйфатлар рәвешендә гыйлем-акыл, әдәп-әхлак, күркәм-гүзәл холык, мөлаемлык-мәхәббәтлелек кат-кат искәртелә. Автор гаиләне «кечкенә бер дәүләт» итеп карый, аның матди һәм рухи тотрыклыгы нигезләренең ике затка да бәйле булуын гәүдәләндерә. Яшәеш үзәгенә Кешене куеп, гыйлем белән күркәм холыкны башка сыйфатларга нигез итеп карый. Шуңа да укыту системасын үзгәртеп кору актив яклана, дини һәм дөньяви белем каршылыкта түгел, бәлки бергәлектә, кеше өчен икесе дә кирәкле сыйфат итеп бәяләнә. Әдипнең әдәби-эстетик, дини-этик, фәлсәфи карашларын чагылдырган мәсьәлә буларак, ислам диненә бәйле карашлар киң урын ала, әсәрләрдәге үрнәк геройлар шәригать кануннары буенча яши һәм моның аларга көчышаныч, таяныч-терәк булып торуы кат-кат искәртелә.

## ЧЫГАНАКЛАР ҺӘМ МАТЕРИАЛЛАР

Валидов 1998 – Валидов Дж. Очерк истории образованности и литературы татар. Казань: Изд-во «Иман», 1998.

Миңнегулов 2004 – Миңнегулов Х. Түрәләрнең мәгънәви рәһбәре // Мәдәни җомга. 20 февраль 2004.

Тукай 2016 – Тукай Г.М. Әхмәт Урманчеевка // Тукай Г.М. Әсәрләр: 6 томда. 5 т.: мәсәлләр, балалар өчен хикәяләр, автобиографик повесть, юлъязмалар, хатлар (1903–1913) / Төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. Г.А. Хөснетдинова, Г.М. Ханнанова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. Б. 231–232.

Фәхреддин 2018 – Фәхреддин Р. Сәлимә, яки Гыйффәт: романнар, мәкаләләр. Казан: Рухият, 2018.

Фәхреддин 1999 – Фәхреддин Р. Тәрҗемәи хәлем // Ризаэддин Фәхреддин: Фәнни-биографик җыентык / Төз. Р. Мәрданов, Р. Миңнуллин, С. Рәхимов. Казан: Рухият, 1999. Б. 7–38.

## ФӘННИ ӘДӘБИЯТ

Бәширов Ф. Р. Фәхреддинов прозасында тәрбия һәм әхлак мәсьәләләре // Ризаэддин Фәхреддин: мирасы һәм хәзерге заман: Мәкаләләр җыентыгы / Редколлегия: Р.М. Әмирханов һ.б. Казан: ТР ФА Тарих институты нәшр., 2003. Б. 232–238.

Габидуллина Ф.И. Эволюция просветительских идей в татарской прозе начала XX века // Европейское обозрение общественных наук. 2016. Т. 3. № 4. С. 5–28.

Гайнетдинов М. Риза Фәхреддиновның иҗат пафосы // Ризаэддин Фәхреддин: мирасы һәм хәзерге заман: Мәкаләләр җыентыгы / Редколлегия: Р.М. Әмирханов һ.б. Казан: ТР ФА Тарих институты нәшр., 2003. Б. 219–231.

Ганиева Р.К. Декадентские мотивы в татарской литературе (первая четверть XX в.) // Милли мәдәният. 2005. № 7. С.10–16.

Даутов Г.Ф. Ризаэддин Фәхреддин – әдип һәм әдәбиятчы. Филология фәннәре кандидаты гыйльми дәрәҗәсен алу өчен язылган диссертация. Казан, 2001.

Закирзянов А.М. Современное татарское литературоведение: достижения, проблемы и перспективы развития // Национальные литературы на современном этапе: научные концепции и гипотезы: круглый стол, посвященный 80-летию создания Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан: сб.ст. Вып.1 / сост.: А.Ф. Ганиева, Ф.Х. Миннуллина, Л.Р. Надыршина. Казань: ИЯЛИ, 2019. С. 80–88.

Исхаков Д.М. Феномен татарского джадидизма: введение к социокультурному осмыслению. Казань: Изд-во «Иман», 1997.

Миңнегулов Х.Й. Милли каһарманыбыз // Гасырлар өнен тыңлап... Казан: Мәгариф, 2003. Б. 108–113(а).

Миңнегулов Х.Й. Ризаэддин Фәхреддин – әдип һәм әдәбиятчы // Гасырлар өнен тыңлап... Казан: Мәгариф, 2003. Б. 120–129(б).

Очерки истории татарской общественной мысли. Казань: Татар. кн. изд-во, 2000.

Шәрәф Ә. Әткәем турында истәлекләр // Ризаэддин Фәхреддин: Фәнни-биографик җыентык (Төз. – Р. Мәрданов, Р. Миңнуллин, С. Рәхимов). Казан: Рухият, 1999. Б. 45–78.

Юзеев А.И. Татарская философская мысль конца XVIII – XIX вв. Казань: Татар. кн. изд-во, 2001.

**Автор турында белешмә:** Закирҗанов Әлфәт Мәгъсүмҗан улы – филология фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге мөдире (420111, Карл Маркс ур., 12, Казан, Россия Федерациясе); alfat_zak@mail.ru

*Редакциягә керде 10.03.2020* *Басылуга кабул ителде 02.11.2020*
*Басылды 25.11.2020*

## THE AESTHETICS OF THE ENLIGHTENMENT IN THE WORKS OF R. FAKHREDDIN

***A.M. Zakirzyanov***

*G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art*
*of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*alfat_zak@mail.ru*

In the middle of the XIX century, an educational movement to renew society based on education and moral education begins in places where Tatars lived in compact numbers. Having adopted these ideas, writers looked for ways and means to bring their views to the masses. Rizaeddin Fakhreddin, who made a significant contribution to the development of the Tatar Renaissance, in the stories *“Salima”* and *“Asma”* refers to the events of reality and brings to the foreground an educated, idealized hero who acts in the interests of the people. The author considers changes in society in close connection with the fate of women. In the stories, Islamic values were depicted in close relationship with Russian-European achievements. The writer puts a moral, educated person to the Universe’s center, in whose actions the author's religious-ethical, philosophical-aesthetic views are also expressed.

**Keywords:** enlightenment, Tatar literature, Rizaeddin Fakhreddin, the fate of women, family, literary and aesthetic view, Islamic values

**For citation:** Zakirzyanov A.M. Rizaeddin Fäkhreddinneñ ijatynda mäg"rifätchelek estetikasy chagylyshy [The Aesthetics of the Enlightenment in the Works of Rizaeddin Fakhreddin]. *Istoricheskaya etnologiya*, 2020, vol. 5, no. 2, pp. 293–305. https://doi.org/10.22378/he.2020-5-2.293-305

## REFERENCES

Bäshirov F. Rizaeddin Fäkhreddinov prozasında tärbiyä häm äkhlak mäs'äläläre [Issues of Education and Morality in Rizaeddin Fakhretdin's Prose]. *Rizaeddin Fäkhreddin: mirası häm häzerge zaman: Mäkalälär cıentıgı* / Ed: R.M. Amirkhanov at all. Kazan: RT Academy of Sciences Institute of History Publ., 2003, pp. 219–231. (In Tatar)

Validov D. *Ocherk istorii obrazovannosti i literatury tatar* [An Essay on the History of Education and Literature of Tatars]. Kazan: Iman Publ. House, 1998. (In Russian)

Gabidullina F.I. Evolyutsiya prosvetitel'skikh idey v tatarskoy proze nachala XX veka [The Evolution of Educational Ideas in the Tatar Prose of early 20th century]. *Evropeyskoe obozreniye obtchestvennyh nauk,* 2016, Vol. 3, no. 4, pp. 5–28. (In Russian)

Gaynetdinov M. Riza Fäkhreddinneñ icat pafosı [The Pathos of Riza Fakhreddin`s Creativity] *Rizaeddin Fäkhreddin: mirasy häm häzerge zaman: Mäkalälär cıentıgı* / Ed.: R.M. Amirkhanov et all. Kazan: RT Academy of Sciences Institute of History Publ., 2003, pp. 219–231. (In Tatar)

Ganieva R. Dekadentskiye motivy v tatarskoy literature (pervaya chetvert' XX veka) [Decadent Motives in the Tatar Literature (the First Quarter of the 20th Century)]. *Milli Mädäniyät,* 2005, no. 7, pp. 10–16. (In Tatar)

Dautov G.F. Rizaeddin Fäkhreddin – ädip häm ädäbiyatchı. Filol. fən. kand. diss. [Rizaeddin Fakhreddin – a Writer and a Specialist in Literature. Cand. Sc. Philol. Diss.]. Kazan, 2001. (In Tatar)

Zakirzyanov A. Sovremennoe tatarskoye literatorovedeniye: dostizheniya, problemy i perspektivy razvitiya [Contemporary Tatar Literary Studies: Achievements, Problems and Prospects for Development]. *Natsional'nyye literatury na sovremennom etape: nauchnyye kontseptsii i gipotezy: kruglyi stol, posvyashchennyi 80-letiyu sozdaniya Instituta yazyka, literatury i iskusstva im. G. Ibragimova Akademii nauk Respubliki Tatarstan: sb. st.* Vol.1. Kazan, 2019, pp. 80–88. (In Russian)

Iskhakov D.M. *Fenomen tatarskogo dzhadidizma: vvedeniye k sotsiokul'turnomu osmysleniyu* [The Phenomenon of Tatar Jadidism: an Introduction to Socio-cultural Understanding]. Kazan: Iman Publ. House, 1997. (In Russian)

Minnegulov Kh.J. Milli kakharmanıbız [Our National Hero]. *Gasırlar önen tıñlap...* Kazan, 2003, pp. 108–113(a). (In Tatar).

Minnegulov Kh.J. Rizaeddin Fäkhreddin – ädip häm ädäbiyatçı [Rizaeddin Fakhreddin – a Writer and a Specialist in Literature]. *Gasırlar önen tıñlap...* Kazan, 2003, pp. 120–129(б). (In Tatar)

*Ocherki istorii tatarskoy obshchestvennoj mysli* [Essays on the History of Tatar Social Thought]. Kazan: Tatar Book Publ., 2000. (In Russian)

Shäräf A. Ätkäem turında istäleklär [Memories of My Father]. *Fänni-biografik cıentık.* Töz. – R. Märdanov, R. Miñnullin, S. Räkhimov. Kazan: Rukhiyat, 1999, pp. 45–78. (In Tatar)

Yuzeyev A.I. *Tatarskaya filosofskaya mysl' kontsa XVIII – XIX vv.* [The Tatar Philosophical Thought of late 18th – 19th centuries]. Kazan: Tatar Book Publ., 2001. (In Russian)

*Закиржҗанов Ә.М.* Ризаэддин Фәхреддиннең иҗатында
мәгърифәтчелек эстетикасы чагылышы

**About the author**: Alfat M. Zakirzyanov is a Doctor Sc. (Phililogy), Head of the Department for Literary Studies, G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art of the Tatarstan Academy of Sciences (12 Karl Marks St., Kazan 420011, Russian Federation); alfat_zak@mail.ru

*Received March 10, 2020* *Accepted for publication November 02, 2020*
*Published November 25, 2020*

## ЭСТЕТИКА ПРОСВЕТИТЕЛЬСТВА В ТВОРЧЕСТВЕ Р. ФАХРЕДДИНА

***А.М. Закирзянов***

*Институт языка, литературы и искусства*
*им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*alfat_zak@mail.ru*

В середине XIX века в местах компактного проживания татар началось просветительское движение, цель которого состояла в обновлении общества на почве просвещения и нравственного воспитания. Писатели, вооружившись этими идеями, искали пути и средства для их доведения до народных масс. Внесший большой вклад в развитие татарского Возрождения, Ризаэддин Фахреддин в повестях *«Салима»* и *«Асма»* обращается к реальным событиям и на передний план выводит образованного, воспитанного, радеющего за интересы народа идеализированного героя. Общественные изменения автор рассматривает в тесной связи с судьбой женщин. В повестях исламские ценности изображаются в тесной взаимосвязи с русско-европейскими достижениями. В центр Вселенной писатель ставит нравственного, образованного Человека, в действиях которого отражаются авторские религиозно-этические и философско-эстетические взгляды.

**Ключевые слова:** просветительство, татарская литература, Ризаэддин Фахреддин, судьба женщины, семья, литературно-эстетический взгляд, исламские ценности

**Для цитирования:** Закирзянов А.М. Ризаэддин Фәхреддиннең иҗатында мәгърифәтчелек эстетикасы чагылышы // Историческая этнология. 2020. Т. 5, № 2. С. 293–305. https://doi.org/10.22378/he.2020-5-2.293-305

**Сведения об авторе:** Закирзянов Альфат Магсумзянович – доктор филологических наук, заведующий отделом литературоведения Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан (420011, ул. Карла Маркса, 12, Казань, Российская Федерация); alfat_zak@mail.ru

*Поступила 10.03.2020* *Принята к публикации 02.11.2020*
*Опубликована 25.11.2020*